**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Зур Кукмара авыл җирлеге аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлегe сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зур Кукмара авыл җирлегендәге Жилой Рудник поселогының Төзелеш урамы 7 Б йорт янындагы балалар уен мәйданчыгы территориясендә һәм «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зур Кукмара авыл җирлегендәге Жилой Рудник поселогындагы эпизоотия чыганагы чикләреннән 1 км радиустагы территориядә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Зур Кукмара авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2022 елның 29 августындагы ПУ-607 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ ПУ-779